КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 июнь

г.Казань

№ 413

Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 60$^{9}$ статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләү, урманнарда эшләрнең билгеле бер төрләрен башкару тәртибен һәм Урманнарда санитария иминлеген тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләү, урманнарда эшләрнең билгеле бер төрләрен башкару тәртибен раслау турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 457 нче боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә зарарлы организмнар чыганакларын бетерү чараларын үткәрүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай урманчылыгындагы Азнакай участок урманчылыгының 67, 68, 73, 74, 80, 86 – 90, 118 – 120, 122 – 126, 132 – 137, 139, 140, 142, 143, 147, 152, 155, 157 – 159, 162, 163, 165, 166, 181, 185 – 188, 192, 194, 196, 199, 201, 202 кварталлары, Җәлил участок урманчылыгының 43, 46, 47, 52, 56 кварталлары, Мәлбагыш участок урманчылыгының 6, 12, 18, 31, 43, 47, 123 – 126, 136 кварталлары, Сарман участок урманчылыгының 29 кварталы, Чатыртау участок урманчылыгының 16, 17, 21 – 23, 26 – 28, 32 – 34, 39, 40, 47 – 51, 57 – 60, 62 – 64, 66, 76, 77 кварталлары, Баулы урманчылыгындагы Баулы участок урманчылыгының 4, 5, 10, 12, 15 – 17, 20 – 29, 117, 125 – 131, 133, 134, 159, 339, 344, 351 кварталлары, Кандыз

участок урманчылыгының 173, 174, 176, 184, 187, 191, 197 – 199, 201, 202, 204, 210, 216 – 220, 223, 224, 226, 229 – 235, 237, 238, 244, 268, 270 – 272, 274, 280, 284, 302, 307, 313, 317, 328, 336, 337 кварталлары, Болгар урманчылыгындагы Никольский участок урманчылыгының 9, 35, 37, 39, 41, 44, 50 – 54, 56, 85 – 88, 116 кварталлары, Спас участок урманчылыгының 14, 19 – 21, 26, 27, 33, 44, 63 – 65, 78, 79, 81, 83 кварталлары, Бөгелмә урманчылыгындагы Актүбә участок урманчылыгының 32, 43, 47, 48, 50, 53, 56, 59, 61, 68, 69, 77 – 79, 94 кварталлары, Бөгелмә участок урманчылыгының 1, 2, 4 – 8, 21, 29, 30, 44, 50, 52, 61, 62, 64, 100, 102, 110, 115 кварталлары, Петровский участок урманчылыгының 73 – 79, 102 – 105, 107, 108 кварталлары, Ютазы участок урманчылыгының 31 – 36, 47 – 49, 51, 53 – 58, 60 – 64, 76, 78, 79, 85, 86, 91, 93, 95, 99, 102 – 104, 106 – 111, 114, 116, 119, 122, 131 – 133, 137 – 142, 149, 161, 180, 185, 190 – 192, 217, 218, 221 кварталлары, Лениногорск урманчылыгындагы Лениногорск участок урманчылыгының 1 – 7, 11, 13 – 15, 18, 19, 21 – 28, 30, 33 – 36, 42 – 47, 50 – 60, 62 – 65, 69, 73, 136 кварталлары, Зәй-Каратай участок урманчылыгының 30 – 35, 37, 38, 42, 65 – 74, 76, 77 кварталлары чикләрендә урман фонды территориясендә әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 21 календарь көнгә кадәр урманнарда санитария иминлеген тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын, аларга транспорт чаралары белән керүен һәм аларда билгеләнгән эшләр башкаруын чикләү кертергә.

2. Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү чорына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү максаты белән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең төбәк диспетчерлык хезмәтенә элемтәгә керү өчен түбәндәге телефон номерын билгеләргә: 8(843) 221-37-95.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

эшләр башкарыла торган районлагы урманнардан файдаланучы затларга зарарлы организмнарның чыганакларын бетерү чараларын үткәрүгә бәйле рәвештә урманнарда булуны вакытлыча чикләү хакында әлеге чикләү башланганга кадәр 10 көн кала тапшыру турындагы хәбәрнамә кәгазе белән хәбәр итүне оештырырга;

эшләр башкару урыннарында эшкәртү участогы чикләреннән 300 метр (җир өсте эшкәрткәндә) һәм 500 метр (авиация эшкәртүендә) ераклыкта бердәм кисәтү аншлаглары урнаштыруны оештырырга;

үтү һәм йөрү өчен, шулай ук терлекне үткәрү өчен эшкәртелергә тиешле урман кишәрлекләре аша үтә торган юлларны ябуны оештырырга;

эшкәртелергә тиешле урман кишәрлекләрендә урманнардан файдалануның барлык төрләрен туктатып торуны оештырырга;

зарарлы организмнарны юкка чыгару яки аларның санын киметү чараларын башкаруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасының Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Сарман, Спас, Ютазы муниципаль районнары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

җирле халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары (җирле газета, радио, телевидение, өндәмәләр) аша урманнарда булуны вакытлыча чикләү турында хәбәр итүне, зарарлы организмнарның чыганакларын бетерү чараларын үткәрү, файдаланыла торган препаратлар турында мәгълүмат күрсәтеп, урман корткычларыннан сакланырга тиешле урман кишәрлекләрен препаратлар белән эшкәртү сроклары, иҗтимагый иминлек чаралары һәм җирле халык, теләсә кайсы формаларга бәйсез рәвештә төрле оешмалар тарафыннан башкарылырга тиешле карантин кагыйдәләре турында мәгълүмат бирүне оештыруны;

эчә торган су чыганакларын препаратлар эләгүдән саклау буенча чаралар күрүне.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында» 2024 ел, 18 май, 336 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин